һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, Олы Әтнә – Чыпчык автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, Ташлы Кавал – Сосновка – Бөреле тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,9 км төньяк-көнчыгышка таба Шимяковка елгасына кадәр бара, 850 м әлеге елга агымы буенча аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба, 300 м көньяк-көнчыгышка таба, берничә мәртәбә кибеп баручы инешне, текә ярны һәм урман полосасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 450 м әлеге инеш агымы буенча аска таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 400 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 200 м әлеге инеш агымы буенча аска таба Ташлы Кавал, Бөреле һәм Усад авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Туктамыш авылыннан 2,7 км көньяк-көнбатышта Крылай елгасында урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ташлы Кавал авыл җирлеге чиге Усад авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, «Ары урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 75 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км төньякка таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 300 м урман полосасы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 800 м әлеге инеш агымы буенча аска таба Крылай елгасына кадәр уза, 30 м әлеге елга агымы буенча аска таба 35 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Биектау муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
25 нче кушымта

**Биектау муниципаль районының «Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Усад авыл җирлеге Әлдермеш, Каенлык, Бөреле, Красносельский, Ташлы Кавал һәм Чернышевка авыл җирлекләре белән чиктәш.

Усад авыл җирлеге чиге Әлдермеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Усад, Әлдермеш һәм Каенлык авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимофеевка авылыннан 300 м көньякта Сола елгасында урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып, Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 900 м Сола елгасы агымы буенча аска таба Усад, Әлдермеш һәм Чернышевка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимофеевка авылыннан 1,0 км көньяк-көнбатышта Сола елгасында урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Усад авыл җирлеге чиге Каенлык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Усад, Каенлык һәм Ташлы Кавал авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Өнсә авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасыннан алып 500 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көньякка таба 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Инсинка елгасына кадәр уза, 50 м әлеге елга агымы буенча аска таба аңа инеш койган җиргә кадәр бара, 2,2 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, алга таба 500 м көньяк-көнбатышка таба, 650 м төньяк-көнбатышка таба авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнчыгышка таба «Ары урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 500 м көнбатышка таба әлеге урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 50 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, 600 м көньяк-көнбатышка таба 80 нче урман кварталының төньяк, төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап инешкә кадәр уза, 450 м әлеге инеш агымы буенча аска таба бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 750 м урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Усад авыл җирлеге чиге Ташлы Кавал авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, «Ары урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 75 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км төньякка таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 300 м урман полосасы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 800 м әлеге инеш агымы буенча аска таба Крылай елгасына кадәр уза, 30 м әлеге елга агымы буенча аска таба Усад, Ташлы Кавал һәм Бөреле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Туктамыш авылыннан 2,7 км көньяк-көнбатышта Крылай елгасында урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Усад авыл җирлеге чиге Бөреле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып 250 м Крылай елгасы агымы буенча аска таба уза, алга таба 700 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньякка таба 100 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 11 нче урман кварталының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, шуннан соң 800 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км 13 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш, көньяк һәм көньяк-

көнчыгыш чикләре буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, көньякка таба 450 м чокыр төбе буенча, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 16 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 250 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Крылай елгасына кадәр уза, 350 м әлеге елга агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, 1,7 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары 50 м төньяк-көнбатышка таба һәм 400 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 1,6 км көнбатышка таба урман полосасы буйлап 15 нче урман кварталына кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба 500 м әлеге урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 15 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 100 м көньяк-көнчыгышка таба 173 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м көнчыгышка таба, 200 м көньяк-көнчыгышка таба, 750 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, текә ярны кисеп үтеп, 650 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м 17 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, алга таба 50 м әлеге инеш агымы буенча аска таба Бимерка инеше белән кушылган җиргә кадәр бара, 950 м әлеге инеш агымы буенча аска таба уза, аннары, урман утыртмаларын кисеп үтеп, 750 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньякка таба 300 м әлеге урман утыртмаларының көнбатыш чиге буйлап, 50 м текә ярның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң күмәк бакчаларның төньяк чиге буенча 100 м көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньякка таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чиге буйлап 950 м көньяк-көнбатышка таба уза, 900 м көнбатышка таба текә ярның төньяк чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 950 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казансу елгасына кадәр бара, 1,8 км әлеге елга агымы буенча өскә таба уза, алга таба, агач-куак яр буе массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба һәм 150 м көньякка таба Усад, Бөреле һәм Красносельский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чубар авылыннан 1,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Усад авыл җирлеге чиге Красносельский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 1,4 км «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 54 нче, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 400 м көньяк-көнбатышка таба 53 нче, 52 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 52 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 50 м 52 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Казансу елгасына кадәр уза, 850 м әлеге елга агымы буенча аска таба бара, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, көньяк-көнчыгышка таба 100 м Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км 52 нче урман кварталының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап Усад, Красносельский һәм Чернышевка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чубар авылыннан 550 м көньяк-көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Усад авыл җирлеге чиге Чернышевка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып 5,4 км Сола елгасы агымы буенча аска таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, 950 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сола елгасына кадәр бара, 1,2 км әлеге елга агымы буенча аска таба аның Казансу елгасына койган җиренә кадәр уза, 250 м әлеге елга агымы буенча аска таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м яр буе агач-куак массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м яр буе агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, Усад спирт заводы – Чернышевка – Каймар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 40 м көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казансу елгасының элеккеге үзәненең төньяк ярына кадәр бара, 950 м көнчыгышка таба әлеге яр буйлап 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Биектау муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
26 нчы кушымта

**Биектау муниципаль районының «Чыпчык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Чыпчык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чыпчык авыл җирлеге Бөреле, Иске Казан, Коркачык, Мүлмә, Шәпше һәм Ямаширмә авыл җирлекләре белән чиктәш.

Чыпчык авыл җирлеге чиге Бөреле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чыпчык, Бөреле һәм Мүлмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ташлы Кавал авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 450 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 7 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, Олы Әтнә – Чыпчык автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,7 км 170 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 170 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнбатышка таба, 750 м көньяк-көнчыгышка таба, чокырларны кисеп үтеп, 1,1 км көньякка таба, сынык сызык ясап, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 950 м көньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 1,1 км әлеге инеш агымы буенча аска таба Казансу елгасына кадәр бара, 250 м әлеге елга агымы буенча аска таба уза, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 100 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,8 км төньяк-көнбатышка таба 20 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, сынык сызык ясап, 1,1 км

төньяк-көнчыгышка таба 18 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньякка таба 100 м 18 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м үләт чокырының көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м 18 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 50 м 18 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 3,2 км көньяк-көнбатышка таба 18, 19, 23 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 300 м төньяк-көнчыгышка таба 22 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, 22 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба һәм 300 м төньякка таба бара, аннары 250 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 22 нче урман кварталының төньяк чиге буенча 150 м көнбатышка таба һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м көньяк-көнбатышка таба бара, 21 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 250 м төньяк-көнбатышка таба һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба 21 нче, 24 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 20 м көньяк-көнбатышка таба яр буе агач-куак массивы буйлап Казансу елгасына кадәр уза, 1,6 км әлеге елга агымы буенча аска таба Ташлы Кавал – Сосновка – Бөреле тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, 1,4 км әлеге автомобиль юлы буйлап уза, аннары 200 м көньяк-көнбатышка таба күмәк бакчалар буйлап бара, Ташлы Кавал – Сосновка – Бөреле тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км күмәк бакчаларның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, әлеге полоса буйлап 30 м, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 450 м әлеге урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман полосасын кисеп үтеп, 100 м көньякка таба бара, шуннан соң 250 м көньяк-көнбатышка таба Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап бара, көньяк-көнчыгышка таба 250 м урман полосасы буйлап, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 250 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба Чыпчык,

Бөреле һәм Шәпше авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимошкино авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 63 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чыпчык авыл җирлеге чиге Мүлмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чыпчык, Мүлмә һәм Коркачык авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Коркачык тимер юл разъезды поселогыннан 150 м төньякта Казансу елгасында урнашкан 51 нче тоташу ноктасыннан алып, текә ярны кисеп үтеп, 250 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 750 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 30 нчы, 29 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 150 м 29 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 2,7 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м 170 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 300 м төньякка таба 7 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 48 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чыпчык авыл җирлеге чиге Коркачык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чыпчык, Коркачык һәм Иске Казан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Коркачык тимер юл разъезды поселогыннан 550 м көньякта урнашкан 50 нче тоташу ноктасыннан алып 1,2 км көньяк-көнбатышка таба Казан – Малмыж автомобиль юлы буйлап инешкә кадәр уза, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 600 м әлеге инеш агымы буенча аска таба аның Казансу елгасына койган җиренә кадәр бара, 1,7 км әлеге елга агымы буенча өскә таба 51 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чыпчык авыл җирлеге чиге Иске Казан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 50 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м көньякка таба һәм 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба Коркачык – Югары Ия автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Чыпчык, Иске Казан һәм Ямаширмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ямаширмә авылыннан 800 м төньяк-көнбатышта урнашкан 64 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чыпчык авыл җирлеге чиге Ямаширмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 64 нче тоташу ноктасыннан алып, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,5 км

көнбатышка таба урман полосасының төньяк чиге буйлап инешкә кадәр уза, 150 м әлеге инеш агымы буенча аска таба Чыпчык, Ямаширмә һәм Шәпше авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ямаширмә авылыннан 1,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 65 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чыпчык авыл җирлеге чиге Шәпше авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 65 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап, Сидоров инешен кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 40 м төньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 600 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, күлне кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, текә ярларны, Яңа Чишмә инешен, «Казан – Малмыж» – Шәпше автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм аның юл буе урман полосаларын кисеп үтеп, 3,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 1,6 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 63 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Биектау муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>27 нче кушымта

## Биектау муниципаль районының «Чернышевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Чернышевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чернышевка авыл җирлеге Әлдермеш, Олы Кавал, Дачный, Красносельский һәм Усад авыл җирлекләре белән чиктәш.

Чернышевка авыл җирлеге чиге Дачный авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чернышевка, Дачный һәм Красносельский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дачный поселогыннан 250 м көнчыгышта Казансу елгасында урнашкан 43 нче тоташу ноктасыннан алып, инешне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 100 м агач-куак массивы буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Каймарка елгасына кадәр уза, 5,6 км шушы елга агымы буенча өскә таба бара, 30 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 250 м көньяк-көнбатышка таба «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биектау участок урманчылыгындагы 181 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, сынык сызык ясап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м көнбатышка таба 181 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 150 м 181 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, сынык сызык ясап, 1,0 км көнбатышка таба 181 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары 300 м төньяк-көнбатышка таба урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 1,1 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 100 м төньяк-көнбатышка таба урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м текә ярның көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м текә ярның көньяк чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, «Мәскәү – Уфа» – Әлдермеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырны кисеп үтеп, 1,6 км төньякка таба, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба уза, 100 м төньякка таба 180 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары агач-куак массивының көнбатыш чиге буенча төньякка таба 40 м, төньяк чиге буйлап 50 м көнчыгышка таба уза, сынык сызык ясап, 250 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 300 м көньяк-көнбатышка таба 180 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, 400 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 300 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м 183 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 58 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 500 м әлеге урман кварталы буйлап бара, аннары көнбатышка таба 450 м 58 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, урман массивын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 180 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап Чернышевка, Дачный һәм Олы Кавал авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Теплый Ключ авылыннан 1,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чернышевка авыл җирлеге чиге Олы Кавал авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чернышевка, Олы Кавал һәм Әлдермеш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Теплый Ключ авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 200 м 79 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 150 м 79 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 28 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чернышевка авыл җирлеге чиге Әлдермеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чернышевка, Әлдермеш һәм Усад авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимофеевка авылыннан 1,0 км көньяк-көнбатышта Сола елгасында урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып 300 м Саинка елгасы агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, текә ярны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, көньякка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м чокырның көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Потурка инешенә кадәр уза, 2,3 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, төньяк-көнбатышка таба 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, «Мәскәү – Уфа» – Әлдермеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м көньяк-көнбатышка таба авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 250 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, төньякка таба 100 м буа буенча бара, 1,7 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, 850 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 100 м көнбатышка таба «Ары урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап уза, шуннан соң 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 200 м төньяк-көнбатышка таба 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап уза, шуннан соң 79 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 250 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк чиге буйлап 100 м көнбатышка таба һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 950 м көньяк-көнбатышка таба 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Чернышевка авыл җирлеге чиге Усад авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып 5,4 км Сола елгасы агымы буенча аска таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 950 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сола елгасына кадәр бара, 1,2 км әлеге елга агымы буенча аска таба аның Казансу елгасына койган җиренә кадәр уза, 250 м әлеге елга агымы буенча аска таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м яр буе агач-куак массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м яр буе агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, Усад спирт заводы – Чернышевка – Каймар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 40 м көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казансу елгасының элеккеге үзәненең төньяк ярына кадәр бара, әлеге яр буйлап 950 м көнчыгышка таба Чернышевка, Усад һәм Красносельский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чубар авылыннан 550 м көньяк-көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чернышевка авыл җирлеге чиге Красносельский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 45 нче тоташу ноктасыннан алып 250 м көньяк-көнчыгышка таба Казансу елгасының элеккеге үзәненең төньяк-көнчыгыш яры буйлап уза, шуннан соң 700 м көньякка таба «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республи-

касы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 52 нче, 55 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 350 м күмәк бакчаларның көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба 150 м көньяк-көнбатышка таба 55 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, 500 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Казансу елгасының элеккеге үзәненә кадәр бара, 350 м әлеге элеккеге үзән буйлап, 50 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биектау участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 67 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 100 м көнбатышка таба 66 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 66 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, 100 м күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап, 700 м 65 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап Казансу елгасына кадәр бара, 1,2 км әлеге елга агымы буенча аска таба 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

4) 29 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Биектау муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
29 нчы кушымта

**Биектау муниципаль районының «Шәпше авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Шәпше авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Шәпше авыл җирлеге Бөреле, Биектау, Чыпчык, Ямаширмә авыл җирлекләре һәм Питрәч муниципаль районы белән чиктәш.

Шәпше авыл җирлеге чиге Питрәч муниципаль районы белән чиктәш җирдә Шәпше, Ямаширмә авыл җирлекләре һәм Питрәч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Олы Ялан авылыннан 3,9 км көньяк-көнбатышта урнашкан 72 нче тоташу ноктасыннан алып Биектау муниципаль районы чиге буйлап Шәпше, Биектау авыл җирлекләре һәм Питрәч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кызыл Шәрекъ авылыннан 5,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 71 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәпше авыл җирлеге чиге Биектау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәпше, Биектау һәм Бөреле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимошкино авылыннан 2,0 км көньякта урнашкан 62 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 400 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 121 нче, 122 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 2,2 км 122 нче, 123 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, шуннан соң 1,1 км көньякка таба 123 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 1,5 км көнчыгышка таба 131 нче, 132 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 500 м көньякка таба 132 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 400 м 133 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 600 м 133 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 450 м көньякка таба 133 нче урман кварталы буйлап бара, 133 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 400 м көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк чиге буйлап 30 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км 133 нче урман кварталының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары 900 м көньякка таба 132 нче, 139 нчы урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 71 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәпше авыл җирлеге чиге Бөреле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәпше, Бөреле һәм Чыпчык авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимошкино авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 63 нче тоташу ноктасыннан алып 450 м инеш агымы буенча өскә таба уза, 50 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнбатышка таба «Шәһәр яны урманчылыгы»

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 106 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 178 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап бара, аннары 200 м төньяк-көнбатышка таба 106 нчы, 178 нче урман кварталларының аерымланган кишәрлекләренең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 400 м көньяк-көнчыгышка таба 178 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары 200 м көньякка таба 106 нчы, 178 нче урман кварталларының аерымланган кишәрлекләренең көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, урман массивын, буаны, инешне һәм плотинаны кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 167 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 1,2 км көньякка таба 167 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 250 м 167 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м 167 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 62 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Шәпше авыл җирлеге чиге Чыпчык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәпше, Чыпчык һәм Ямаширмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ямаширмә авылыннан 1,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 65 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м күмәк бакчаларның көньяк чиге буйлап, Сидоров инешен кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 40 м төньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 600 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, күлне кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, текә ярларны, Яңа Чишмә инешен, «Казан – Малмыж» – Шәпше автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм аның юл буе урман полосаларын кисеп үтеп, 3,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 1,6 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап, 950 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 63 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәпше авыл җирлеге чиге Ямаширмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 65 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м инеш агымы буенча аска таба, 50 м буаның сулъяк яры буенча, 400 м инеш агымы буенча аска таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, 550 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары көньякка таба 50 м чокыр төбе буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, көньякка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көнбатышка таба һәм 400 м төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 350 м әлеге инеш агымы буенча аска таба бара, сынык сызык ясап, агач-куак массивын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр, 900 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары, сынык сызык ясап, «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 108 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш, көнбатыш, көньяк-көнбатыш чикләре буйлап һәм 110 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 1,5 км бара, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 200 м сазлыкның көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 100 м 110 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,7 км 111 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, 650 м көньякка таба 111 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 150 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 550 м әлеге инеш агымы буенча аска таба уза, шуннан соң 350 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 300 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 600 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көнбатыш

чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 900 м әлеге инеш агымы буенча аска таба бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 3,2 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 1,1 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба башка кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,3 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба плотинага кадәр уза, шуннан соң, плотинаның көньяк-көнчыгыш чиген әйләнеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 40 м, 150 м буаның уңъяк яры буенча бара, 1,1 км инеш агымы буенча өскә таба уза, көньяк-көнбатышка таба 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м чокыр төбе буенча, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 72 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

5) 31 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Биектау муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
31 нче кушымта

**Биектау муниципаль районының «Ямаширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Ямаширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ямаширмә авыл җирлеге Иске Казан, Чыпчык, Шәпше авыл җирлекләре һәм Питрәч муниципаль районы белән чиктәш.

Ямаширмә авыл җирлеге чиге Питрәч муниципаль районы белән чиктәш җирдә Ямаширмә, Иске Казан авыл җирлекләре һәм Питрәч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Ия авылыннан 2,9 км көньяк-көнбатышта урнашкан 66 нчы тоташу ноктасыннан алып Биектау муниципаль районы чиге буйлап Ямаширмә, Шәпше авыл җирлекләре һәм Питрәч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Олы Ялан авылыннан 3,9 км көньяк-көнбатышта урнашкан 72 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямаширмә авыл җирлеге чиге Шәпше авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямаширмә, Шәпше һәм Чыпчык авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ямаширмә авылыннан 1,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 65 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м инеш агымы буенча аска таба, 50 м буаның сулъяк яры буенча, 400 м инеш агымы буенча аска таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, 550 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары көньякка таба 50 м чокыр төбе буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, көньякка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көнбатышка таба һәм 400 м төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, 350 м әлеге инеш агымы буенча аска таба бара, сынык сызык ясап, агач-куак массивын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр, 900 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары, сынык сызык ясап, «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 108 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш, көнбатыш, көньяк-көнбатыш чикләре буйлап һәм 110 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 1,5 км бара, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 200 м сазлыкның көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 100 м 110 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,7 км 111 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, 650 м көньякка таба 111 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 150 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 550 м әлеге инеш агымы буенча аска таба уза, шуннан соң 350 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 300 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 600 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 900 м әлеге инеш агымы буенча аска таба бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 3,2 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 1,1 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба башка кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,3 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба плотинага кадәр уза, шуннан соң, плотинаның көньяк-көнчыгыш чиген әйләнеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 40 м, 150 м буаның уңъяк яры буенча бара, 1,1 км инеш агымы буенча өскә таба уза, көньяк-көнбатышка таба 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м чокыр төбе буенча, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 72 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ямаширмә авыл җирлеге чиге Чыпчык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямаширмә, Чыпчык һәм Иске Казан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ямаширмә авылыннан 800 м төньяк-көнбатышта урнашкан 64 нче тоташу ноктасыннан алып, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,5 км көнбатышка таба урман полосасының төньяк чиге буйлап инешкә кадәр уза, 150 м әлеге инеш агымы буенча аска таба 65 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ямаширмә авыл җирлеге чиге Иске Казан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 64 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 300 м урман полосасы буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м көнчыгышка таба, 150 м көньякка таба, 500 м көнчыгышка таба, инешне кисеп үтеп, 350 м көнчыгышка таба карьер буенча, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 200 м урман полосасы буйлап уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м сазлык буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, 800 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Коркачык – Югары Ия» – Татар Урматы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көньякка таба 350 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 27 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 27 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сы-

нык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 850 м 27 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 300 м көньякка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап Коркачык – Югары Ия автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, 3,1 км көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 400 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 200 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньякка таба 250 м агач-куак үсемлекләре массивының көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 100 м төньяк-көнчыгышка таба сазлыкның көньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, сынык сызык ясап, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 2,0 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, 40 м көньяк-көнчыгышка таба 44 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге һәм 50 м көньяк-көнбатышка таба көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 150 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 150 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 250 м көньякка таба 44 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 66 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.».

## 1372. Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Менделеевск муниципаль районы составына керүче «Менделеевск шәһәре», «Бәзәкә авыл җирлеге», «Енабердино авыл җирлеге», «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

«Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 1,9 км Мамадыш шәһәрен әйләнеп узучы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, юл буе урман полосасын һәм урман массивын кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 50В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап 50 м, 50В, 51В урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,9 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба, 40 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 51В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 800 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м Нократ елгасы ермагының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м күлнең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м күл буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м Нократ елгасы акваториясе буенча исемсез утрауга кадәр уза, шуннан соң 450 м көньяк-көнчыгышка таба исемсез утрау буйлап «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Көек-Ерыкса һәм Отарка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яковка авылыннан 5,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Отарка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып 900 м көньяк-көнчыгышка таба Мамадыш шәһәрен әйләнеп узучы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 3,6 км көньякка таба «Мәскәү – Уфа» – Мамадыш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба, 800 м Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап Нократ елгасына кадәр уза, төньякка таба 7,2 км Нократ елгасының уң яры буйлап, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 100 м төньяк-көнчыгышка таба Нократ елгасына кадәр бара, Нократ елгасы акваториясе буенча 250 м исемсез утрауга кадәр уза, шуннан соң 1,0 км төньяк-көнбатышка таба әлеге утрау буйлап 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Албай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Албай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Албай авыл җирлеге Никифорово, Усали авыл җирлекләре, Балык Бистәсе һәм Теләче муниципаль районнары белән чиктәш.

Албай авыл җирлеге чиге Никифорово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Албай, Никифорово авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Никифорово авылыннан 6,4 км көнбатышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып 3,9 км көньяк-көнчыгышка таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 25, 34, 44 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 450 м көньяк-көнбатышка таба 43 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң 100 м төньяк-көнчыгышка таба урман массивы буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, Арташ инешен кисеп үтеп, 48 нче, 51 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, кибеп баручы инешне ике тапкыр кисеп үтеп, 56 нчы, 62 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,4 км уза, аннары көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шомарбаш участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 750 м уза, шуннан соң 600 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 500 м көньяк-көнбатышка таба 41 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Албай, Никифорово һәм Усали авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында

Олы Арташ авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Албай авыл җирлеге чиге Усали авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 2,1 км көньяк-көнбатышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шомарбаш участок урманчылыгындагы 42 нче, 43 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м чокырның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, Бөрсет елгасы агымы буенча 350 м өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча, Усали – Албай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,4 км өскә таба бара, аннары 550 м төньяк-көнбатышка таба 4 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Албай, Усали авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Түбән Әрнәш авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Албай авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап Албай авыл җирлеге, Балык Бистәсе һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Югары Әрнәш авылыннан 5,8 км көнбатышта урнашкан 1 нче (53 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Албай авыл җирлеге чиге Теләче муниципаль районы белән чиктәш җирдә 1 нче (53 нче) тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-

схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Югары Ушма авыл җирлеге Дүсмәт, Ишки, Көек-Ерыкса, Кече Кирмән, Түбән Ушма һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре белән чиктәш.

Югары Ушма авыл җирлеге чиге Дүсмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Югары Ушма, Дүсмәт һәм Ишки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәсәнша авылыннан 1,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасыннан алып 950 м көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 22 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 250 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, Васильево (Әҗмәк) һәм Алкино авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 3,4 км төньяк-көнчыгышка таба 23 нче, 28 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, шуннан соң 29 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 850 м көньякка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,7 км көнчыгышка таба 30 нчы, 31 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, аннары 750 м төньяк-көнчыгышка таба 31 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 450 м көнчыгышка таба 35 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 35 нче, 36 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 36 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне һәм аның текә ярын кисеп үтеп, 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 36 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м Югары Ушма, Дүсмәт һәм Көек-Ерыкса авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Комазан авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Ушма авыл җирлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып 5,9 км көньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан

Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 37, 46, 52 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 1,0 км көнчыгышка таба 52 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап Югары Ушма, Көек-Ерыкса һәм Түбән Ушма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хафиз авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Югары Ушма авыл җирлеге чиге Түбән Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 2,2 км көньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 54 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, Ушма елгасын һәм «Мамадыш — Теләче» — Хәсәнша автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнбатышка таба бара, Межа инеше агымы буенча, Мамадыш — Теләче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,8 км өскә таба Югары Ушма, Түбән Ушма һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хафиз авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Ушма авыл җирлеге чиге Урта Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 49 нчы, 47 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 47 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 4,5 км төньяк-көнбатышка таба 47, 46, 45, 44, 39 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 1,6 км көньяк-көнбатышка таба 39 нчы, 38 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 3,7 км төньяк-көнбатышка таба 36, 35, 34 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 450 м көньяк-көнбатышка таба 34 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Югары Ушма, Урта Кирмән һәм Кече Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Су-Елга авылыннан 700 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Ушма авыл җирлеге чиге Кече Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 200 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап,

«Мамадыш – Теләче» – Кече Кирмән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Югары Ушма, Кече Кирмән һәм Ишки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Су-Елга авылыннан 900 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Ушма авыл җирлеге чиге Ишки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Мамадыш – Теләче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 7 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 650 м көньякка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк чиге буйлап 350 м көнбатышка таба 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

2) 7 – 12 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мамадыш муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең<br>һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>7 нче кушымта

### Мамадыш муниципаль районының «Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре

чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Дүсмәт авыл җирлеге Югары Ушма, Ишки, Көек-Ерыкса, Олыяз, Тауиле һәм Шәдче авыл җирлекләре белән чиктәш.

Дүсмәт авыл җирлеге чиге Тауиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Дүсмәт, Тауиле һәм Ишки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Васильево (Әҗмәк) авылыннан 1,6 км төньякта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 20 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба, төньяк чиге буйлап 350 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 1,1 км көнчыгышка таба уза, шуннан соң 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба 15 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Дүсмәт, Тауиле һәм Олыяз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Васильево (Әҗмәк) авылыннан 4,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Дүсмәт авыл җирлеге чиге Олыяз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 3,8 км көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 15, 16, 17 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 13 нче, 14 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 2,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 550 м бара, аннары 14 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба һәм 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 6 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньякка таба, 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 650 м көньяк-көнчыгышка таба бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 6 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 350 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 6 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м Дүсмәт, Олыяз һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комазан башы авылыннан 600 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Дүсмәт авыл җирлеге чиге Шәдче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан

участок урманчылыгындагы 7 нче, 8 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап 2,1 км, урман массивының көньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман массивының көньяк чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м уза, көньяк-көнчыгышка таба урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м, 9 нчы урман кварталы буйлап 850 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 9 нчы урман кварталы буйлап 150 м уза, аннары әлеге урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 900 м төньяк-көнбатышка таба һәм 750 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 10 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м көнчыгышка таба, 450 м көньяк-көнбатышка таба һәм 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары әлеге урман кварталы буйлап, сынык сызык ясап, 550 м көньякка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 10 нчы, 11 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 950 м уза, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 500 м Дүсмәт, Шәдче һәм Көек-Ерыкса авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Комазан авылыннан 850 м төньяк-көнбатышта урнашкан 69 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Дүсмәт авыл җирлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 69 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба, чокырларны, Комазан елгасын һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м карьер буйлап уза, аннары «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 27 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк чиге буйлап 500 м көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 900 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 41 нче, 40 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 100 м уза, аннары 600 м көньякка таба 39 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары көнбатышка таба 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км, 37 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км Дүсмәт, Көек-Ерыкса һәм

Югары Ушма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Комазан авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Дүсмәт авыл җирлеге чиге Югары Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Дүсмәт, Югары Ушма һәм Ишки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәсәнша авылыннан 1,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасыннан алып 950 м көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 22 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 250 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, Васильево (Әҗмәк) һәм Алкино авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 3,4 км төньяк-көнчыгышка таба 23 нче, 28 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, шуннан соң 29 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 850 м көньякка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,7 км көнчыгышка таба 30 нчы, 31 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, аннары 750 м төньяк-көнчыгышка таба 31 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 450 м көнчыгышка таба 35 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 35 нче, 36 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 36 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне һәм аның текә ярын кисеп үтеп, 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 36 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Дүсмәт авыл җирлеге чиге Ишки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып 1,7 км көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 22 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 21 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 500 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 20 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м көньяк-көнбатышка таба,

650 м төньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 1,1 км төньяк-көнбатышка таба 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
8 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ишки авыл җирлеге Югары Ушма, Дүсмәт, Кече Кирмән, Никифорово, Сон һәм Тауиле авыл җирлекләре белән чиктәш.

Ишки авыл җирлеге чиге Тауиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ишки, Тауиле һәм Никифорово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нагашево авылыннан 1,9 км көньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасы буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, чокырны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 300 м көньяк-көнбатышка таба чокыр төбе буенча уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Шыя елгасын кисеп үтеп, 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба, Ишки – Түбән Тәкәнеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба, 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба Югары Усы елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 1,6 км өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

Ишки, Тауиле һәм Дүсмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Васильево (Әҗмәк) авылыннан 1,6 км төньякта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Ишки авыл җирлеге чиге Дүсмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ишки, Дүсмәт һәм Югары Ушма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәсәнша авылыннан 1,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасыннан алып 1,7 км көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 22 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 21 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 500 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 20 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м көньяк-көнбатышка таба, 650 м төньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 1,1 км төньяк-көнбатышка таба 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Ишки авыл җирлеге чиге Югары Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Мамадыш – Теләче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 7 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 650 м көньякка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк чиге буйлап 350 м көнбатышка таба Ишки, Югары Ушма һәм Кече Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Су-Елга авылыннан 900 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ишки авыл җирлеге чиге Кече Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып 900 м төньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 7 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 500 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 7 нче, 6 нчы урман кварталла-

рының көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,7 км көньякка таба 14 нче, 17 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,1 км көнбатышка таба 17 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 550 м төньякка таба 17 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, 400 м төньяк-көнбатышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм буаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 150 м төньяк-көнчыгышка таба буаның уң яры буенча уза, аннары, сынык сызык ясап, 850 м төньяк-көнбатышка таба 13 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 200 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 350 м көньяк-көнбатышка таба сәнәгать объектының төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап бара, 300 м көньяк-көнчыгышка таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 16 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, 16 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км уза, шуннан соң 1,4 км көнбатышка таба 16 нчы, 15 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м 18 нче урман кварталы буйлап Ишки, Кече Кирмән һәм Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Сон авылыннан 2,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ишки авыл җирлеге чиге Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ишки, Сон һәм Никифорово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Сон авылыннан 3,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, урман массивының көньяк чиге буйлап 50 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Усали – Югары Сон һәм Мамадыш – Теләче автомобиль юлларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, инешне һәм урман массивын кисеп үтеп, 1,5 км көнчыгышка таба, 350 м

көньяк-көнчыгышка таба инешкә кадәр бара, аның текә ярын кисеп үтә, әлеге инеш агымы буенча 950 м аска таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 9 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм 100 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 9 нчы, 10 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап, Сон елгасын кисеп үтеп, 300 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 100 м, 10 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 10 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба һәм, Сон елгасын кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 800 м көньякка таба, инешне кисеп үтеп, 11 нче, 15 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 18 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ишки авыл җирлеге чиге Никифорово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км көньякка таба һәм 950 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 200 м чокырның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба, Шыя елгасын һәм аның текә ярын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, Мамадыш — Теләче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасы буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасы буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 3,7 км көньяк-көнчыгышка таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 55 нче, 61 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мәскәү — Уфа» — Усали — Югары Сон һәм Мамадыш — Теләче автомобиль юлларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 500 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 300 м көньяк-көнчыгышка таба 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне

һәм «Мәскәү — Уфа» — Усали — Югары Сон һәм Мамадыш — Теләче автомобиль юлларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 61 нче, 67 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Катмыш авыл җирлеге Түбән Сон, Урманчы, Усали авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш.

Катмыш авыл җирлеге чиге Усали авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Катмыш, Усали авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Баскан авылыннан 1,2 км көнбатышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 750 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 700 м көнчыгышка таба Бөрсет елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 800 м аска таба Катмыш, Усали һәм Түбән Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Баскан авылыннан 900 м көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Катмыш авыл җирлеге чиге Түбән Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 47 нче тоташу ноктасыннан алып 900 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Бөрсет елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 2,3 км аска таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Кама урман хуҗалыгы – Бөрсет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары урман утыртмалары буенча 50 м көньяк-көнбатышка таба һәм 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, «Мәскәү – Уфа» – Кама урман хуҗалыгы – Бөрсет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны кисеп үтеп, 100 м, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кама участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының аерымланган кишәрлекләренең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,8 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, сазлык буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бөрсет елгасына кадәр 100 м уза, әлеге елга агымы буенча 2,2 км аска таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, Бөрсет елгасының текә ярын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак үсемлекләре полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, кибеп баручы инеш агымы буенча 750 м өскә таба бара, аннары 700 м көньякка таба, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Катмыш, Түбән Сон һәм Урманчы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Еникей-Чишмә (Түбән Кыярлы) авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Катмыш авыл җирлеге чиге Урманчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 50 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 900 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Бөрсет елгасын кисеп үтеп, 200 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 850 м уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, «Мәскәү – Уфа» – Кама урман хуҗалыгы – Бөрсет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м

урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кама участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба һәм 100 м көньяк-көнбатышка таба, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Катмыш, Урманчы авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урманчы авылыннан 1,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Катмыш авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 49 нчы тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 48 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Көмешкүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Көмешкүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Көмешкүл авыл җирлеге Keләүш, Түбән Тәкәнеш, Түбән Шүләңгер, Олыяз, Шәдче авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы белән чиктәш.

Көмешкүл авыл җирлеге чиге Keләүш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Көмешкүл, Keләүш авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Алгай авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Keләүш

участок урманчылыгындагы 50 нче урман кварталының төньяк почмагында урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып 500 м көньяк-көнчыгышка таба 50 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 3,0 км төньяк-көнчыгышка таба 51, 52, 53 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 250 м көньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба плотинаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнбатышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнбатышка таба 53 нче, 52 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 4,5 км көньяк-көнчыгышка таба 55, 58, 59, 60, 61 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, аннары 2,0 км көнчыгышка таба 66 нчы, 67 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап Көмешкүл, Келәүш һәм Түбән Шүләңгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарбаш авылыннан 1,0 км көньякта «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көмешкүл авыл җирлеге чиге Түбән Шүләңгер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып 67 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 900 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 450 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньякка таба 68 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап Көмешкүл, Түбән Шүләңгер һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Шүләңгер авылыннан 1,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Көмешкүл авыл җирлеге чиге Шәдче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 68 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 1,0 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм 68 нче урман кварталының көньяк

чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң 900 м төньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне һәм урман массивын кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнбатышка таба һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 66 нчы, 72 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 3,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 72 нче, 71 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 71 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 71 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 150 м бара, аннары көнбатышка таба 70 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнбатышка таба 70 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 73 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м көнбатышка таба һәм 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба уза, 75 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, 75 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км уза, шуннан соң 350 м көнбатышка таба 75 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 75 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 800 м Көмешкүл, Шәдче һәм Олыяз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Козгынчы авылыннан 1,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көмешкүл авыл җирлеге чиге Олыяз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 500 м төньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 75 нче, 74 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м күл буенча уза, Шыя елгасы кушылдыгы агымы буенча 200 м өскә таба бара, Шыя елгасы агымы буенча, Түбән Тәкәнеш – Көмешкүл – Олыяз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,6 км өскә таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км төньяк-көнбатышка таба һәм, чокырны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, 300 м көньякка таба бара, Шыя елгасы агы-

мы буенча 300 м өскә таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 2 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, урман полосасы буйлап 200 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба, 650 м төньякка таба һәм 350 м көнбатышка таба Көмешкүл, Олыяз һәм Түбән Тәкәнеш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көмешкүл авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Көмешкүл авыл җирлеге чиге Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, Түбән Тәкәнеш – Көмешкүл – Олыяз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, урман полосасы буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, урман полосасы буйлап 150 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км төньяк-көнбатышка таба һәм 500 м төньяк-көнчыгышка таба Көмешкүл, Түбән Тәкәнеш авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Тәкәнеш авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Көмешкүл авыл җирлеге чиге Кукмара муниципаль районы белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Келәүш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Келәүш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Келәүш авыл җирлеге Көмешкүл, Түбән Шүләңгер авыл җирлекләре, Кукмара муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Келәүш авыл җирлеге чиге Көмешкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Келәүш, Көмешкүл авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Алгай авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 50 нче урман кварталының төньяк почмагында урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып 500 м көньяк-көнчыгышка таба 50 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 3,0 км төньяк-көнчыгышка таба 51, 52, 53 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 250 м көньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба плотинаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнбатышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнбатышка таба 53 нче, 52 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 4,5 км көньяк-көнчыгышка таба 55, 58, 59, 60, 61 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, аннары 2,0 км көнчыгышка таба 66 нчы, 67 нче урман

кварталларының төньяк чиге буйлап Келәүш, Көмешкүл һәм Түбән Шүләңгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарбаш авылыннан 1,0 км көньякта «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Келәүш авыл җирлеге чиге Кукмара муниципаль районы белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап Келәүш авыл җирлеге, Кукмара муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Гурьевка авылыннан 2,8 км көньяк-көнчыгышта Нократ елгасы акваториясендә урнашкан 70 нче (15 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Келәүш авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 70 нче (15 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Келәүш, Түбән Шүләңгер авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Березовая Поляна поселогыннан 300 м төньякта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Келәүш авыл җирлеге чиге Түбән Шүләңгер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча 1,4 км өскә таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 95, 93, 90 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м бара, аннары 650 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, аның текә ярын кисеп үтә, әлеге инеш агымы буенча 2,2 км аска таба аның Юкәче елгасына койган җиренә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 250 м өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Келәүш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньяк-көнбатышка таба һәм, чокырны кисеп үтеп, 1,9 км төньяк-көнбатышка таба 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Красная Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Красная Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Красная Горка авыл җирлеге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Түбән Ушма, Омар, Отарка, Урта Кирмән һәм Уразбахты авыл җирлекләре белән чиктәш.

Красная Горка авыл җирлеге чиге Түбән Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Красная Горка, Түбән Ушма һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Ушма авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 600 м урман полосасы буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мамадыш – Теләче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба, 750 м көньяк-көнчыгышка таба, Мамадыш – Теләче – Түбән Ушма автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 50 м аска таба Ушма елгасына кадәр бара, 1,7 км Ушма елгасы агымы буенча аска таба Красная Горка, Түбән Ушма авыл җирлекләре һәм «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташ-

кан урында Красная Горка авылыннан 150 м төньякта Ушма елгасында урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Красная Горка авыл җирлеге чиге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Красная Горка авыл җирлеге, «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Отарка авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Красная Горка авылыннан 1,5 км көньякта Беркас елгасында урнашкан 59 нчы тоташу ноктасыннан алып Беркас елгасы агымы буенча, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,9 км аска таба уза, аннары 100 м төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап юллар чатына кадәр бара, шуннан соң төньякка таба башка профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 400 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Ушма елгасын кисеп үтеп, 500 м бара, аннары 150 м көнбатышка таба Ушма елгасының сул яры буенча аңа инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 1,2 км өскә таба бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 750 м көнбатышка таба, инешнең текә ярын кисеп үтеп, сәнәгать объектының төньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 350 м көньякка таба, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 400 м канау буенча, сынык сызык ясап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ушма елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 650 м өскә таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көнбатышка таба, 350 м төньяк-көнбатышка таба Ушма елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 350 м өскә таба бара, Ушма елгасының элеккеге юлы буенча 500 м уза, әлеге елга агымы буенча 50 м өскә таба 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Красная Горка авыл җирлеге чиге Отарка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып Беркас елгасы агымы буенча, Мамадыш шәһәрен әйләнеп узучы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 900 м өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, аның агымы буенча 1,7 км өскә таба бара, шуннан соң 1,7 км көньякка таба, урман полосасын һәм Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Соколка участок урманчылыгындагы 41В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көнбатышка таба, 50 м көньякка таба уза, 650 м 41В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең

көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көнбатышка таба, 50 м көньякка таба уза, шуннан соң 250 м көньяк-көнбатышка таба 41В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап бара, 37В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, аннары Пакшин елгасы агымы буенча 5,3 км аска таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 400 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 700 м көньяк-көнчыгышка таба, берничә тапкыр чокырларны кисеп үтеп, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 100 м инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 400 м агач-куак полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Красная Горка, Отарка һәм Омар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керәшен Пакшины авылыннан 1,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 62 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Красная Горка авыл җирлеге чиге Омар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 62 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м көнбатышка таба агач-куак полосасының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Керәшен Пакшины һәм Югары Сикәнәс авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, 50 м көнбатышка таба уза, 150 м урман массивы буйлап бара, аннары Пакшин елгасы агымы буенча 3,5 км аска таба аңа Кутушка елгасы койган җиргә кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 1,0 км өскә таба бара, шуннан соң көнбатышка таба, агач-куак үсемлекләренең яр буе массивын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, аның текә ярын кисеп үтә, аннары әлеге инеш агымы буенча 2,2 км өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, аны кисеп үтеп, 50 м урман полосасы буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары чокырларны һәм Кутушка елгасының текә ярын кисеп

үтеп, сынык сызык ясап, 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Кутушка елгасы агымы буенча 2,0 км өскә таба уза, шуннан соң 40 м көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Соколка участок урманчылыгындагы 39В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Сикәнәс автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,7 км көнбатышка таба, агач-куак полосаларын кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнчыгышка таба Красная Горка, Омар һәм Уразбахты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Кирмәне авылыннан 2,7 км көньякта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Красная Горка авыл җирлеге чиге Уразбахты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 56 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, сынык сызык ясап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешнең текә ярын кисеп үтеп уза, әлеге инеш агымы буенча 800 м аска таба бара, шуннан соң 100 м төньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньякка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м төньякка таба һәм 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң инеш агымы буенча 400 м өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба чокыр буенча 150 м, 37В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м бара, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман массивы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, 37В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба һәм, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м Красная Горка, Уразбахты һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Кирмәне авылыннан

3,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Красная Горка авыл җирлеге чиге Урта Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м төньяк-көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 900 м төньякка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 4,0 км төньяк-көнбатышка таба 66, 64, 58, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба 51, 52, 54 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 54 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м төньяк-көнчыгышка таба уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 54 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км 40 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.»;

3) 14 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Югары Ушма, Дүсмәт, Түбән Ушма, Түбән Шүләңгер, Отарка, Шәдче авыл җирлекләре, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Дүсмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Көек-Ерыкса, Дүсмәт һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Комазан авылыннан 850 м төньяк-көнбатышта урнашкан 69 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба, чокырларны, Комазан елгасын һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м карьер буйлап уза, аннары «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 27 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк чиге буйлап 500 м көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 900 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 41 нче, 40 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 100 м уза, аннары 600 м көньякка таба 39 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары көнбатышка таба 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км, 37 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км Көек-Ерыкса, Югары Ушма һәм Дүсмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Комазан авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Шәдче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 69 нчы тоташу ноктасыннан алып «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 700 м көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,0 км төньяк-көнбатышка таба, төньяк чиге буйлап 150 м көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,9 км төньяк-көнбатышка таба 3 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Keләүш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 4,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Көек-Ерыкса, Шәдче һәм Түбән

Шүләңгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каргалы авылыннан 600 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Түбән Шүләңгер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Шыя елгасы агымы буенча 1,2 км аска таба уза, шуннан соң көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 3В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 200 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м көньякка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба уза, инешне кисеп үтеп, 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң инеш агымы буенча 150 м аска таба Шыя елгасы кушылдыгына кадәр бара, аннары аның агымы буенча 800 м аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м бара, 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 200 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км төньякка таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м карьер буенча, 106 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км бара, аннары 2,6 км төньяк-көнбатышка таба 106 нчы, 105 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м һәм 400 м көнчыгышка таба Көек-Ерыкса, Түбән Шүләңгер авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Чиркәс авылыннан 3,2 км төньяк-көнбатышта «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталының көнчыгыш почмагында урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Көек-Ерыкса авыл җирлеге, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Чиркәс авылыннан 2,5 км төньякта Нократ елгасы акваториясендә урнашкан 74 нче (16 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә 74 нче (16 нчы) тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап Көек-Ерыкса, Отарка авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Мамадыш шәһәренең төньяк-көнчыгыш чигеннән 2,8 км төньяк-көнчыгышта Анзирка елгасында урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Отарка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Көек-Ерыкса, Отарка авыл җирлекләре һәм «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Яковка авылыннан 5,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба исемсез утрау буенча 150 м Нократ елгасына кадәр, әлеге елга акваториясе буенча 500 м уза, шуннан соң көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 33В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,4 км, сазлыкны кисеп үтеп, 33В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, сазлык буенча 100 м, 32В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 600 м Анзирка елгасына кадәр, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Көек-Ерыкса авыл җирлеге, «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Түбән Ушма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Ушма авылыннан 3,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 1,9 км Мамадыш шәһәрен әйләнеп узучы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, Мамадыш — Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, юл буе урман полосасын һәм урман массивын кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 50В урман кварталының көньяк-

көнбатыш чиге буйлап 400 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 50В, 51В урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,9 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба, 40 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 51В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 800 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м Нократ елгасы ермагының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м күлнең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м күл буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м Нократ елгасы акваториясе буенча исемсез утрауга кадәр уза, шуннан соң 450 м көньяк-көнчыгышка таба исемсез утрау буйлап 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Түбән Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Көек-Ерыкса, Түбән Ушма һәм Югары Ушма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хафиз авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 52 нче, 47 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,9 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м, 47 нче, 48 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 1,0 км уза, аннары 350 м көньяк-көнчыгышка таба 48 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба 49 нчы, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,1 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 53 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба, 500 м көньякка таба уза, аннары 50 м көньяк-көнчыгышка таба чокыр төбе буенча бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча 800 м аска таба аның инешкә койган җиренә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 900 м аска таба башка инеш белән кушылган җиренә кадәр бара, аның агымы буенча 350 м өскә

таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешнең текә ярын һәм чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 700 м көнчыгышка таба 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Югары Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып 5,9 км көньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 37, 46, 52 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 1,0 км көнчыгышка таба 52 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 35 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

4) 16 – 24 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
16 нчы кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Кече Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кече Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картасхемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кече Кирмән авыл җирлеге Югары Ушма, Ишки, Түбән Сон, Урта Кирмән, Сон һәм Яке авыл җирлекләре белән чиктәш.

Кече Кирмән авыл җирлеге чиге Ишки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Кирмән, Ишки һәм Югары Ушма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Су-Елга авылыннан 900 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасыннан алып 900 м төньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 7 нче урман кварталының

көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 500 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 7 нче, 6 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,7 км көньякка таба 14 нче, 17 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,1 км көнбатышка таба 17 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 550 м төньякка таба 17 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, 400 м төньяк-көнбатышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм буаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 150 м төньяк-көнчыгышка таба буаның уң яры буенча уза, аннары, сынык сызык ясап, 850 м төньяк-көнбатышка таба 13 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 200 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 350 м көньяк-көнбатышка таба сәнәгать объектының төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап бара, 300 м көньяк-көнчыгышка таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 16 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, 16 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км уза, шуннан соң 1,4 км көнбатышка таба 16 нчы, 15 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м 18 нче урман кварталы буйлап Кече Кирмән, Ишки һәм Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Сон авылыннан 2,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Кирмән авыл җирлеге чиге Югары Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Кирмән, Югары Ушма һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Су-Елга авылыннан 700 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 200 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, «Мамадыш — Теләче» — Кече Кирмән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Кирмән авыл җирлеге чиге Урта Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Кирмән, Урта Кирмән һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Норма авылыннан 2,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, «Мәскәү — Уфа» — Урта Кирмән — Кече Кирмән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Кирмән елгасын кисеп үтеп, 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба, 600 м төньякка таба бара, 450 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 250 м көньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 2,0 км төньякка таба 41 нче, 40 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 40 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, 40 нчы, 37 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,6 км төньякка таба 36 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,0 км көньяк-көнбатышка таба 35 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 2,2 км төньяк-көнбатышка таба, сазлыкны кисеп үтеп, 34 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Кирмән авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Кирмән, Яке һәм Түбән Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Яке авылыннан 1,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, урман массивын кисеп үтеп, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Түбән Яке һәм Югары Яке авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Омар елгасын кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап,

сынык сызык ясап, 1,1 км уза, аннары 50 м төньяк-көнбатышка таба 76 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 76 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м уза, аннары, Югары Яке һәм Урта Кирмән авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м төньяк-көнбатышка таба, 75 нче, 73 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,6 км бара, шуннан соң 700 м төньякка таба 73 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 800 м төньяк-көнбатышка таба, көнбатыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 800 м төньякка таба бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба 72 нче, 70 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба 70 нче, 71 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң 1,1 км көньякка таба 71 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 600 м көньяк-көнчыгышка таба 74 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 43 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кече Кирмән авыл җирлеге чиге Түбән Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Кирмән, Түбән Сон һәм Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Яке авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 34, 35, 37 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 3,2 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 37, 39, 43 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 3,6 км 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Кирмән авыл җирлеге чиге Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 20 нче, 22 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,2 км, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 22 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап

200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 150 м, 22 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м бара, аннары 25 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 600 м көньякка таба һәм 700 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба 25 нче, 27 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 2,5 км, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 27 нче, 29 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 32 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,1 км, Кече Сон һәм Югары Яке авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
17 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Түбән Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Ушма авыл җирлеге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Югары Ушма, Красная Горка, Көек-Ерыкса һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре белән чиктәш.

Түбән Ушма авыл җирлеге чиге Югары Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Ушма, Югары Ушма һәм Көек-Ерыкса авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хафиз авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 35 нче

тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 2,2 км төньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 54 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, Ушма елгасын һәм «Мамадыш – Теләче» – Хәсәнша автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнбатышка таба бара, Межа инеше агымы буенча, Мамадыш – Теләче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,8 км өскә таба Түбән Ушма, Югары Ушма һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хафиз авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Ушма авыл җирлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 52 нче, 47 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,9 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м, 47 нче, 48 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 1,0 км уза, аннары 350 м көньяк-көнчыгышка таба 48 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба 49 нчы, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,1 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 53 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба, 500 м көньякка таба уза, аннары 50 м көньяк-көнчыгышка таба чокыр төбе буенча бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча 800 м аска таба аның инешкә койган җиренә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 900 м аска таба башка инеш белән кушылган җиренә кадәр бара, аның агымы буенча 350 м өскә таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешнең текә ярын һәм чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 700 м көнчыгышка таба Түбән Ушма, Көек-Ерыкса авыл җирлекләре һәм «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Түбән Ушма авылыннан 3,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Ушма авыл җирлеге чиге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Түбән Ушма авыл җирлеге, «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Красная Горка авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Красная Горка авылыннан 150 м төньякта Ушма елгасында урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып 2,8 км төньякка таба Мамадыш шәһәрен әйләнеп узучы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Ушма авыл җирлеге чиге Красная Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Ушма, Красная Горка һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Ушма авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 600 м урман полосасы буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мамадыш – Теләче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба, 750 м көньяк-көнчыгышка таба, Мамадыш – Теләче – Түбән Ушма автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 50 м аска таба Ушма елгасына кадәр бара, Ушма елгасы агымы буенча 1,7 км аска таба 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Ушма авыл җирлеге чиге Урта Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 3,4 км көньяк-көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 49, 51, 52, 54 нче урман кварталларының төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
18 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Түбән Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Сон авыл җирлеге Катмыш, Кече Кирмән, Сон, Урманчы, Усали һәм Яке авыл җирлекләре белән чиктәш.

Түбән Сон авыл җирлеге чиге Усали авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Сон, Усали һәм Катмыш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Баскан авылыннан 900 м көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасыннан алып Бөрсет елгасы агымы буенча 2,0 км аска таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,8 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Сон, Усали һәм Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Сон авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Сон авыл җирлеге чиге Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Сон, Сон һәм Кече Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Яке авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасыннан алып

450 м төньяк-көнбатышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 34 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 34 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 34 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 3,2 км көньякка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 34, 35, 36, 38 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, шуннан соң 40 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 950 м көньяк-көнбатышка таба һәм 600 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 40 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 350 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 250 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,2 км аска таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, «Мәскәү – Уфа» – Түбән Сон – Кече Сон автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Сон елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м төньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 800 м төньяк-көнбатышка таба уза, 11 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м 46 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Сон авыл җирлеге чиге Кече Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 45 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 34, 35, 37 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 3,2 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 37, 39, 43 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 3,6 км Түбән Сон, Кече Кирмән һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Яке авылыннан 1,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Сон авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет

учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 43 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м, 43, 47, 48 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 48 нче, 50 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км бара, аннары 50 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньякка таба, көньяк чиге буйлап 1,5 км көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Дегетле елгасын кисеп үтеп, 800 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, 49 нчы, 52 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 52 нче, 54 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,8 км бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба 59 нчы, 62 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба 62 нче, 64 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары 400 м көнбатышка таба 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,0 км көньякка таба 67 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап Түбән Сон, Яке һәм Урманчы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дегетле авылыннан 3,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 51 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Сон авыл җирлеге чиге Урманчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 51 нче тоташу ноктасыннан алып 4,8 км төньяк-көнбатышка таба, Карамалка инешен кисеп үтеп, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 67, 66, 65 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 550 м төньяк-көнчыгышка таба 65 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,1 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Сон, Урманчы һәм Катмыш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Еникей-Чишмә авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Сон авыл җирлеге чиге Катмыш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 47 нче тоташу ноктасыннан алып 900 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Бөрсет елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 2,3 км аска таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Кама урман хуҗалыгы – Бөрсет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары урман утыртмалары буенча 50 м көньяк-көнбатышка таба һәм 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, «Мәскәү – Уфа» – Кама урман хуҗалыгы – Бөрсет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны кисеп үтеп, 100 м, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кама участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының аерымланган кишәрлекләренең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,8 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, сазлык буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бөрсет елгасына кадәр 100 м уза, әлеге елга агымы буенча 2,2 км аска таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, Бөрсет елгасының текә ярын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак үсемлекләре полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, кибеп баручы инеш агымы буенча 750 м өскә таба бара, аннары 700 м көньякка таба, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең<br>һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>19 нчы кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картасхемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турын-

да» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Көмешкүл, Олыяз, Шәмәк авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы белән чиктәш.

Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге чиге Көмешкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Тәкәнеш, Көмешкүл һәм Олыяз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көмешкүл авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, Түбән Тәкәнеш – Көмешкүл – Олыяз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, урман полосасы буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, урман полосасы буйлап 150 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км төньяк-көнбатышка таба һәм 500 м төньяк-көнчыгышка таба Түбән Тәкәнеш, Көмешкүл авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Тәкәнеш авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге чиге Олыяз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,2 км көньякка таба чокыр төбе буенча бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Оча елгасын кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м көнбатышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба бара, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,1 км көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап Түбән Тәкәнеш, Олыяз һәм Шәмәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Тәкәнеш авылыннан 650 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге чиге Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба, Ишки – Түбән Тәкәнеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,1 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

1,2 км, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мишәбаш участок урманчылыгындагы 374 нче, 373 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,0 км бара, аннары 1,1 км көньяк-көнбатышка таба 373 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 400 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Түбән Тәкәнеш, Шәмәк авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Чәбия авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге чиге Кукмара муниципаль районы белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Түбән Шүләңгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Шүләңгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Көмешкүл, Келәүш, Көек-Ерыкса, Шәдче авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Түбән Шүләңгер авыл җирлеге чиге Көмешкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Шүләңгер, Көмешкүл һәм Келәүш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарбаш авылыннан 1,0 км көньякта «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок

урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып 67 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 900 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 450 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньякка таба 68 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап Түбән Шүләңгер, Көмешкүл һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Шүләңгер авылыннан 1,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Шүләңгер авыл җирлеге чиге Келәүш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Шүләңгер, Келәүш авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Березовая Поляна поселогыннан 300 м төньякта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча 1,4 км өскә таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 95, 93, 90 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м бара, аннары 650 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, аның текә ярын кисеп үтә, әлеге инеш агымы буенча 2,2 км аска таба аның Юкәче елгасына койган җиренә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 250 м өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Келәүш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньяк-көнбатышка таба һәм, чокырны кисеп үтеп, 1,9 км төньяк-көнбатышка таба 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Түбән Шүләңгер, Көек-Ерыкса авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Чиркәс авылыннан 3,2 км төньяк-көнбатышта «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчы-

лыгындагы 104 нче урман кварталының көнчыгыш почмагында урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Шүләңгер авыл җирлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Шүләңгер, Көек-Ерыкса һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каргалы авылыннан 600 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Шыя елгасы агымы буенча 1,2 км аска таба уза, шуннан соң көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 3В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 200 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м көньякка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба уза, инешне кисеп үтеп, 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң инеш агымы буенча 150 м аска таба Шыя елгасы кушылдыгына кадәр бара, аннары аның агымы буенча 800 м аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м бара, 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 200 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км төньякка таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м карьер буенча, 106 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км бара, аннары 2,6 км төньяк-көнбатышка таба 106 нчы, 105 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м һәм 400 м көнчыгышка таба 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Шүләңгер авыл җирлеге чиге Шәдче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Шыя елгасы агымы буенча 2,3 км өскә таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба һәм, агач-куак полосасын кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап 50 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Келәүш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, канауны кисеп үтеп, 150 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буенча, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м уза, шуннан соң төньякка таба, дамбаны һәм «Мамадыш – Кукмара» – Келәүш – Шәдче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м зират буенча бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,7 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнбатышка таба һәм 900 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Никифорово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турын-

да» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Никифорово авыл җирлеге Албай, Ишки, Сон, Тауиле, Усали авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы белән чиктәш.

Никифорово авыл җирлеге чиге Тауиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Никифорово, Тауиле авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Никифорово авылыннан 4,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 4 нче тоташу ноктасыннан алып 2,0 км көньяк-көнчыгышка таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 20 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 450 м төньякка таба 21 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,6 км көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 50 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 18 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 550 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 950 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 19 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары көнчыгышка таба 250 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 58 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 850 м урман полосасы буйлап, 100 м урман полосасының төньяк чиге буйлап Никифорово, Тауиле һәм Ишки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нагашево авылыннан 1,9 км көньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Никифорово авыл җирлеге чиге Ишки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км көньякка таба һәм 950 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 200 м чокырның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба, Шыя елгасын һәм аның текә ярын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, Мамадыш – Теләче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасы буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасы буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 3,7 км көньяк-көнчыгышка таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 55 нче, 61 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Усали – Югары Сон һәм Мамадыш – Теләче автомобиль юлларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 500 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 300 м көньяк-көнчыгышка таба 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне һәм «Мәскәү – Уфа» – Усали – Югары Сон һәм Мамадыш – Теләче автомобиль юлларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 61 нче, 67 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Никифорово, Ишки һәм Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Сон авылыннан 3,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Никифорово авыл җирлеге чиге Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып 2,4 км көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, шуннан соң 2,1 км төньяк-көнбатышка таба 67 нче, 66 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, аннары 650 м төньякка таба 66 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 65 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,7 км төньяк-көнбатышка таба һәм 300 м көньяк-көнбатышка таба Никифорово, Сон һәм Усали авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сәртек авылыннан 3,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Никифорово авыл җирлеге чиге Усали авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 65 нче, 64 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 64 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м уза, 3,2 км «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шо-

марбаш участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Никифорово, Усали һәм Албай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Арташ авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Никифорово авыл җирлеге чиге Албай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Никифорово, Албай авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Никифорово авылыннан 6,4 км көнбатышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып 3,9 км көньяк-көнчыгышка таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 25, 34, 44 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 450 м көньяк-көнбатышка таба 43 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары 100 м төньяк-көнчыгышка таба урман массивы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, Арташ инешен кисеп үтеп, 48 нче, 51 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, кибеп баручы инешне ике тапкыр кисеп үтеп, 56 нчы, 62 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,4 км уза, аннары көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шомарбаш участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 750 м уза, шуннан соң 600 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 500 м көньяк-көнбатышка таба 41 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Никифорово авыл җирлеге чиге Теләче муниципаль районы белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
22 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Олыяз авыл җирлеге Дүсмәт, Көмешкүл, Түбән Тәкәнеш, Тауиле, Шәдче һәм Шәмәк авыл җирлекләре белән чиктәш.

Олыяз авыл җирлеге чиге Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олыяз, Түбән Тәкәнеш һәм Көмешкүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көмешкүл авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,2 км көньякка таба чокыр төбе буенча бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Оча елгасын кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м көнбатышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба бара, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,1 км көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап Олыяз, Түбән Тәкәнеш һәм Шәмәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Тәкәнеш авылыннан 650 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олыяз авыл җирлеге чиге Көмешкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олыяз, Көмешкүл һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Козгынчы авылыннан 1,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып

500 м төньяк-көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 75 нче, 74 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м күл буенча уза, Шыя елгасы кушылдыгы агымы буенча 200 м өскә таба бара, Шыя елгасы агымы буенча, Түбән Тәкәнеш – Көмешкүл – Олыяз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,6 км өскә таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,9 км төньяк-көнбатышка таба һәм, чокырны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, 300 м көньякка таба бара, Шыя елгасы агымы буенча 300 м өскә таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 2 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, урман полосасы буйлап 200 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба, 650 м төньякка таба һәм 350 м көнбатышка таба 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олыяз авыл җирлеге чиге Шәдче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 30 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнбатышка таба, 250 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көнчыгышка таба һәм 50 м көньякка таба Шыя елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 2,4 км аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 2,1 км көньякка таба, «Мамадыш – Кукмара» – Ямаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 7 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 450 м көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 2,1 км көньякка таба Олыяз, Шәдче һәм Дүсмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комазан башы авылын-

нан 600 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Олыяз авыл җирлеге чиге Дүсмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олыяз, Дүсмәт һәм Тауиле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Васильево (Әҗмәк) авылыннан 4,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 3,8 км көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 15, 16, 17 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 13 нче, 14 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 2,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 550 м бара, аннары 14 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба һәм 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 6 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньякка таба, 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 650 м көньяк-көнчыгышка таба бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 6 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 350 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 6 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Олыяз авыл җирлеге чиге Тауиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 58 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,0 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 56 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м уза, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны һәм урман массивын кисеп үтеп, 56 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м бара, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Олыяз, Тауиле һәм Шәмәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тауиле авылыннан

1,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олыяз авыл җирлеге чиге Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 56 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, чокыр төбе буенча 200 м уза, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча 1,0 км аска таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешнең текә ярын кисеп үтеп, 30 м төньяк-көнчыгышка таба, инешне кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 650 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнбатышка таба Шыя елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 3,4 км аска таба аның Баш-Арбаш елгасы белән кушылган җиренә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 350 м өскә таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба һәм 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м зират буенча бара, аннары 650 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»<br>
муниципаль берәмлегенең<br>
һәм аның составындагы<br>
муниципаль берәмлекләрнең<br>
территорияләре чикләрен билгеләү<br>
һәм аларның статусы турында»<br>
Татарстан Республикасы Законына<br>
23 нче кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Омар авыл җирлеге Красная Горка, Отарка, Соколка, Уразбахты, Яке авыл җирлекләре, Түбән Кама һәм Чистай муниципаль районнары белән чиктәш.

Омар авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Омар, Яке авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Покровский авылыннан 2,4 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 67 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап уза, шуннан соң әлеге сусаклагыч яры буенча 950 м көнбатышка таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сазлыкны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөрсет участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км уза, шуннан соң Заборная елгасы агымы буенча 4,2 км өскә таба бара, аннары инеш агымы буенча 4,3 км өскә таба уза, шуннан соң 350 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак массивларын кисеп үтеп, инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 600 м өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, кибеп баручы инеш агымы буенча 2,1 км өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 250 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча 1,5 км аска таба башка кибеп баручы инеш белән кушылган җиренә кадәр уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 1,3 км өскә таба бара, шуннан соң 1,4 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары инеш агымы буенча 1,9 км аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Омар, Яке һәм Уразбахты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дегетле авылыннан 3,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Омар авыл җирлеге чиге Уразбахты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 54 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырны һәм инешнең текә ярын кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, әлеге инеш агымы буенча 2,7 км аска таба бара, аннары Омар елгасы агымы буенча 4,4 км өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр уза, аның агымы буенча 2,6 км өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын, инешнең текә ярын һәм чокырны ки-

сеп үтеп, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 250 м көнчыгышка таба уза, 850 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м чокыр буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 150 м бара, аннары Кирмән елгасы агымы буенча 1,7 км өскә таба уза, шуннан соң көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 150 м, 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 200 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба Омар, Уразбахты һәм Красная Горка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Кирмәне авылыннан 2,7 км көньякта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Омар авыл җирлеге чиге Красная Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Омар, Красная Горка һәм Отарка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керәшен Пакшины авылыннан 1,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 62 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м көнбатышка таба агач-куак полосасының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Керәшен Пакшины һәм Югары Сикәнәс авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, 50 м көнбатышка таба уза, 150 м урман массивы буйлап бара, аннары Пакшин елгасы агымы буенча 3,5 км аска таба аңа Кутушка елгасы койган җиргә кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 1,0 км өскә таба бара, шуннан соң көнбатышка таба, агач-куак үсемлекләренең яр буе массивын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, аның текә ярын кисеп үтә, аннары әлеге инеш агымы буенча 2,2 км өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, аны кисеп үтеп, 50 м урман по-

лосасы буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары чокырларны һәм Кутушка елгасының текә ярын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Кутушка елгасы агымы буенча 2,0 км өскә таба уза, шуннан соң 40 м көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Соколка участок урманчылыгындагы 39В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Сикәнәс автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,7 км көнбатышка таба, агач-куак полосаларын кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнчыгышка таба 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Омар авыл җирлеге чиге Отарка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Омар, Отарка һәм Соколка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Грахань авылыннан 3,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 61 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча 2,7 км аска таба аның кибеп баручы инеш белән кушылган җиренә кадәр уза, аның агымы буенча 700 м өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба, яр буе агач-куак полосасын кисеп үтеп, 400 м чокыр төбе буенча уза, чокырларны, инешләрне һәм аларның текә ярларын кисеп үтеп, 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 62 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Омар авыл җирлеге чиге Соколка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 61 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Соколка участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 37 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба уза, 3 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м һәм көньякка таба 450 м бара, аннары 200 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 3, 5, 8 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 3,4 км бара, аннары 35 нче урман кварталы буйлап 850 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 700 м төньяк-көнбатышка таба 4 нче урман кварталы буйлап бара, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 1,4 км аска таба уза, шуннан соң 1,0 км

көнчыгышка таба 4 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 2,1 км көньякка таба 7 нче, 12 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 250 м көньяк-көнчыгышка таба 12 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 18 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң, күлне кисеп үтеп, 100 м, 40 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м бара, аннары 18 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 200 м көньякка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба уза, күлне кисеп үтеп, 100 м, 18 нче, 19 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 19 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м бара, шуннан соң көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 19 нчы, 24 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 400 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 150 м көньяк-көнбатышка таба, сазлыкны, күлләрне һәм яр буе агач-куак массивларын кисеп үтеп, 600 м көньяк-көнчыгышка таба, 42 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 20 м уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 31 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, шуннан соң 31 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба бара, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 31 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 40 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 50 м күл буенча уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, күлне берничә тапкыр кисеп үтеп, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м күлнең төньяк-көнбатыш яры буенча, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 450 м көнчыгышка таба 31 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр уза, шуннан соң әлеге сусаклагыч яры буенча 2,3 км көньяк-көнбатышка таба

бара, аннары 850 м көньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча Омар, Соколка авыл җирлекләре һәм Түбән Кама муниципаль районы чикләре тоташкан урында Соколка урманчылыгы поселогыннан 5,7 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 64 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Омар авыл җирлеге чиге Түбән Кама муниципаль районы белән чиктәш җирдә 64 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап Омар авыл җирлеге, Түбән Кама һәм Чистай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Вандовка авылыннан 6,8 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 73 нче (60 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Омар авыл җирлеге чиге Чистай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 73 нче (60 нчы) тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 67 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
24 нче кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Отарка авыл җирлеге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Красная Горка, Көек-Ерыкса, Омар, Соколка авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы белән чиктәш.

Отарка авыл җирлеге чиге Красная Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Отарка, Красная Горка авыл җирлекләре һәм «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Красная Горка авылыннан 1,5 км көньякта Беркас

«Мамадыш муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең<br>һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>32 нче кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Урманчы авыл җирлеге Катмыш, Түбән Сон, Яке авыл җирлекләре, Балык Бистәсе һәм Чистай муниципаль районнары белән чиктәш.

Урманчы авыл җирлеге чиге Катмыш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урманчы, Катмыш һәм Түбән Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Еникей-Чишмә авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 900 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Бөрсет елгасын кисеп үтеп, 200 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 850 м уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, «Мәскәү — Уфа» — Кама урман хуҗалыгы — Бөрсет автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш

чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кама участок урманчылыгындагы 76 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба һәм 100 м көньяк-көнбатышка таба, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Урманчы, Катмыш авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урманчы авылыннан 1,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Урманчы авыл җирлеге чиге Түбән Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урманчы, Түбән Сон һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дегетле авылыннан 3,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 51 нче тоташу ноктасыннан алып 4,8 км төньяк-көнбатышка таба, Карамалка инешен кисеп үтеп, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 67, 66, 65 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 550 м төньяк-көнчыгышка таба 65 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,1 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Урманчы авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 51 нче тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньякка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 72 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км көньякка таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м, 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөрсет участок урманчылыгындагы 11 нче, 12 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 12, 11, 19 нчы урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,5 км көньяк-көнбатышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м һәм 19 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба 19 нчы, 28 нче урман квар-

талларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба 28 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 28 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, аның агымы буенча 250 м аска таба Кече Бөрсет елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 4,3 км аска таба уза, аннары 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба 53 нче, 54 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 54 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 1,7 км көнбатышка таба бара, шуннан соң 54 нче, 53 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,3 км төньяк-көнбатышка таба, 50 м ишелмәләр буенча Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр уза, аннары әлеге сусаклагыч акваториясе буйлап 950 м көньяк-көнбатышка таба Урманчы, Яке авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сухой Берсут поселогыннан 1,0 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 68 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урманчы авыл җирлеге чиге Чистай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 68 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап Урманчы авыл җирлеге, Балык Бистәсе һәм Чистай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Бөрсет авылыннан 1,4 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 52 нче (59 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Урманчы авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 52 нче (59 нчы) тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 49 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
33 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Усали авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Усали авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Усали авыл җирлеге Албай, Катмыш, Түбән Сон, Никифорово, Сон авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш.

Усали авыл җирлеге чиге Албай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Усали, Албай һәм Никифорово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Арташ авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 2,1 км көньяк-көнбатышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шомарбаш участок урманчылыгындагы 42 нче, 43 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м чокырның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, Бөрсет елгасы агымы буенча 350 м өскә таба аңа инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча, Усали — Албай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,4 км өскә таба бара, аннары 550 м төньяк-көнбатышка таба 4 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Усали, Албай авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Түбән Әрнәш авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Усали авыл җирлеге чиге Никифорово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Усали, Никифорово һәм Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сәртек авылыннан 3,6 км көньяк-

көнбатышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 65 нче, 64 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 64 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м уза, 3,2 км «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шомарбаш участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Усали авыл җирлеге чиге Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Усали, Сон һәм Түбән Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Сон авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 11, 10, 9, 6 нчы урман кварталларының көньяк, көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Усали – Югары Сон автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 5,0 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 6 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 1,4 км уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 5,8 км төньяк-көнчыгышка таба 7, 3, 2, 1 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км көнбатышка таба, инешне һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнбатышка таба, чокырны һәм инешләрне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 850 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 82 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 200 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 900 м төньякка таба уза, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Усали авыл җирлеге чиге Түбән Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Усали, Түбән Сон һәм Катмыш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Баскан авылыннан 900 м көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасыннан алып Бөрсет елгасы агымы буенча 2,0 км аска таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең

Усали участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,8 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 46 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Усали авыл җирлеге чиге Катмыш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Усали, Катмыш авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Баскан авылыннан 1,2 км көнбатышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 750 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 700 м көнчыгышка таба Бөрсет елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 800 м аска таба 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Усали авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 48 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
34 нче кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм

аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Шәдче авыл җирлеге Дүсмәт, Көмешкүл, Көек-Ерыкса, Түбән Шүләңгер һәм Олыяз авыл җирлекләре белән чиктәш.

Шәдче авыл җирлеге чиге Көмешкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәдче, Көмешкүл һәм Түбән Шүләңгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Шүләңгер авылыннан 1,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 68 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 1,0 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм 68 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң 900 м төньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне һәм урман массивын кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнбатышка таба һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 66 нчы, 72 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 3,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 72 нче, 71 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 71 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 71 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 150 м бара, аннары көнбатышка таба 70 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнбатышка таба 70 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 73 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м көнбатышка таба һәм 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба уза, 75 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, 75 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км уза, шуннан соң 350 м көнбатышка таба 75 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 75 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 800 м Шәдче, Көмешкүл һәм Олыяз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Козгынчы авылыннан 1,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәдче авыл җирлеге чиге Түбән Шүләңгер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәдче, Түбән Шүләңгер һәм Көек-Ерыкса авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каргалы авылыннан 600 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Шыя елгасы агымы буенча 2,3 км өскә таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба һәм, агач-куак полосасын кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, «Мамадыш — Кукмара» — Келәүш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, канауны кисеп үтеп, 150 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буенча, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м уза, шуннан соң төньякка таба, дамбаны һәм «Мамадыш — Кукмара» — Келәүш — Шәдче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м зират буенча бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,7 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнбатышка таба һәм 900 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәдче авыл җирлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәдче, Көек-Ерыкса һәм Дүсмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Комазан авылыннан 850 м төньяк-көнбатышта урнашкан 69 нчы тоташу ноктасыннан алып «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 700 м көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,0 км төньяк-көнбатышка таба, төньяк чиге буйлап 150 м көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,9 км төньяк-көнбатышка таба 3 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 900 м урман полосасының көньяк-

көнчыгыш чиге буйлап, «Мамадыш — Кукмара» — Келәүш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 4,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шәдче, Көек-Ерыкса һәм Түбән Шүләңгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каргалы авылыннан 600 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәдче авыл җирлеге чиге Дүсмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәдче, Дүсмәт һәм Олыяз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Комазан башы авылыннан 600 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 7 нче, 8 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап 2,1 км, урман массивының көньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман массивының көньяк чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м уза, көньяк-көнчыгышка таба урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м, 9 нчы урман кварталы буйлап 850 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 9 нчы урман кварталы буйлап 150 м уза, аннары әлеге урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 900 м төньяк-көнбатышка таба һәм 750 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 10 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м көнчыгышка таба, 450 м көньяк-көнбатышка таба һәм 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары әлеге урман кварталы буйлап, сынык сызык ясап, 550 м көньякка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 10 нчы, 11 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 950 м уза, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 500 м 69 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәдче авыл җирлеге чиге Олыяз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 30 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнбатышка таба, 250 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көнчыгышка таба һәм 50 м көньякка таба Шыя елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 2,4 км аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара,

аннары, сынык сызык ясап, 2,1 км көньякка таба, «Мамадыш – Кукмара» – Ямаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 7 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 450 м көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 2,1 км көньякка таба 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
35 нче кушымта

## Мамадыш муниципаль районының «Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Шәмәк авыл җирлеге Түбән Тәкәнеш, Олыяз, Тауиле авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы белән чиктәш.

Шәмәк авыл җирлеге чиге Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәмәк, Олыяз һәм Түбән Тәкәнеш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Тәкәнеш авылыннан 650 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба, Ишки – Түбән Тәкәнеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,1 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мишәбаш участок урманчылыгындагы 374 нче, 373 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,0 км бара, аннары 1,1 км көньяк-көнбатышка таба 373 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 400 м төньяк-көнбатышка таба ур-

ман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Шәмәк, Түбән Тәкәнеш авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Чәбия авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Шәмәк авыл җирлеге чиге Олыяз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәмәк, Олыяз һәм Тауиле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тауиле авылыннан 1,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 56 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, чокыр төбе буенча 200 м уза, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча 1,0 км аска таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешнең текә ярын кисеп үтеп, 30 м төньяк-көнчыгышка таба, инешне кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 650 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнбатышка таба Шыя елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 3,4 км аска таба аның Баш-Арбаш елгасы белән кушылган җиренә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 350 м өскә таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба һәм 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м зират буенча бара, аннары 650 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәмәк авыл җирлеге чиге Тауиле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәмәк, Тауиле авыл җирлекләре һәм Кукмара муниципаль районы чикләре тоташкан урында Чаксы авылыннан 650 м төньяк-көнбатышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнчыгышка таба, 400 м көньяк-көнчыгышка таба, 450 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м көньяк-көнбатышка таба һәм 750 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң көньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әбде участок урманчылыгындагы 13 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

300 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м көньяк-көнчыгышка таба Чаксы елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 1,8 км аска таба уза, шуннан соң 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,1 км аска таба аның Чаксы елгасына койган җиренә кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 1,6 км аска таба канауга кадәр бара, аннары канау буенча 250 м Шыя елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 400 м аска таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча, Ишки – Түбән Тәкәнеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м өскә таба уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 600 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 58 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 55 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көнчыгышка таба 150 м урман утыртмалары буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 14 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Шәмәк авыл җирлеге чиге Кукмара муниципаль районы белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Мамадыш муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең<br>һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>36 нчы кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Яке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Яке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яке авыл җирлеге Кече Кирмән, Түбән Сон, Омар, Урта Кирмән, Уразбахты, Урманчы авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы белән чиктәш.

Яке авыл җирлеге чиге Кече Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яке, Кече Кирмән һәм Түбән Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Яке авылыннан 1,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, урман массивын кисеп үтеп, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Түбән Яке һәм Югары Яке авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Омар елгасын кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км уза, аннары 50 м төньяк-көнбатышка таба 76 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 76 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м уза, аннары, Югары Яке һәм Урта Кирмән авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м төньяк-көнбатышка таба, 75 нче, 73 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,6 км бара, шуннан соң 700 м төньякка таба 73 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 800 м төньяк-көнбатышка таба, көнбатыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 800 м төньякка таба бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба 72 нче, 70 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба 70 нче, 71 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң 1,1 км көньякка таба 71 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 600 м көньяк-көнчыгышка таба 74 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Яке, Кече Кирмән һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Норма авылыннан 2,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яке авыл җирлеге чиге Урта Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яке, Урта Кирмән һәм Уразбахты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Кирмәне авылыннан 3,6 км көнбатышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м төньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 82, 80, 79, 77, 76 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне һәм Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 5,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Югары Яке һәм Урта Кирмән авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м, 75 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 450 м бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 75 нче, 74 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 700 м уза, аннары 74 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яке авыл җирлеге чиге Уразбахты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып 850 м көньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 82 нче, 85 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км көнбатышка таба 85 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 85 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,0 км төньяк-көнбатышка таба 85 нче, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 77 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 77 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км уза, 350 м чокыр төбе буенча, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-

көнбатыш чиге буйлап 100 м, кибеп баручы инеш агымы буенча 1,7 км аска таба Омар елгасына кадәр бара, аннары әлеге елга агымы буенча 1,3 км өскә таба кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, аннары әлеге инеш агымы буенча 1,0 км өскә таба уза, шуннан соң 150 м көньякка таба агач-куак массивы буйлап, 200 м текә ярның көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 81 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Яке, Уразбахты һәм Омар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дегетле авылыннан 3,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яке авыл җирлеге чиге Омар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яке, Омар авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Покровский авылыннан 2,4 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 67 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап уза, шуннан соң әлеге сусаклагыч яры буенча 950 м көнбатышка таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сазлыкны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөрсет участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км уза, шуннан соң Заборная елгасы агымы буенча 4,2 км өскә таба бара, аннары инеш агымы буенча 4,3 км өскә таба уза, шуннан соң 350 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак массивларын кисеп үтеп, инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 600 м өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, кибеп баручы инеш агымы буенча 2,1 км өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 250 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча 1,5 км аска таба башка кибеп баручы инеш белән кушылган җиренә кадәр уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 1,3 км өскә таба бара, шуннан соң 1,4 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары инеш агымы буенча 1,9 км аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының

көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яке авыл җирлеге чиге Урманчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яке, Урманчы һәм Түбән Сон авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дегетле авылыннан 3,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 51 нче тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньякка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 72 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км көньякка таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м, 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөрсет участок урманчылыгындагы 11 нче, 12 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 12, 11, 19 нчы урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,5 км көньяк-көнбатышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м һәм 19 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба 19 нчы, 28 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба 28 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 28 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, аның агымы буенча 250 м аска таба Кече Бөрсет елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 4,3 км аска таба уза, аннары 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба 53 нче, 54 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 54 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 1,7 км көнбатышка таба бара, шуннан соң 54 нче, 53 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,3 км төньяк-көнбатышка таба, 50 м ишелмәләр буенча Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр уза, аннары әлеге сусаклагыч акваториясе буйлап 950 м көньяк-көнбатышка таба Яке, Урманчы авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы

чикләре тоташкан урында Сухой Берсут поселогыннан 1,0 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 68 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яке авыл җирлеге чиге Түбән Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 43 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м, 43, 47, 48 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 48 нче, 50 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км бара, аннары 50 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньякка таба, көньяк чиге буйлап 1,5 км көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Дегетле елгасын кисеп үтеп, 800 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, 49 нчы, 52 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 52 нче, 54 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,8 км бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба 59 нчы, 62 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба 62 нче, 64 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары 400 м көнбатышка таба 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,0 км көньякка таба 67 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 51 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яке авыл җирлеге чиге Чистай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 67 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 68 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 30 декабре
№ 138-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

**Муниципаль берәмлекләр чикләренең үзгәрешләр исәпкә алынган карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- Мамадыш муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б –Түбән Ушма авыл җирлегенең һәм «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге

Б-В – Красная Горка авыл җирлегенең һәм «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге

В-Г– Отарка авыл җирлегенең һәм «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге

А-Г – Көек-Ерыкса авыл җирлегенең һәм «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге

- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар

I - Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушма авыл җирлеге территориясе

II - Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Мамадыш муниципаль районының Красная Горка авыл җирлеге территориясе

III - Мамадыш муниципаль районының Красная Горка авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушма авыл җирлеге территориясе

IV - Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәре»муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге территориясе

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

**Муниципаль берәмлекләр чикләренең үзгәрешләр исәпкә алынган карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль берәмлекләр чикләре

- А-Б – Ишки авыл җирлегнең һәм Кече Кирмән авыл җирлегенең чиктәш чиге

- җирлекләрнең административ үзәкләре

- торак пунктлар

- Мамадыш муниципаль районының Кече Кирмән авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге территориясе